# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Березовая Грива авыл торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара
салымын кертү турында

**16.10.2023** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Березовая Грива авыл торак пункты гражданнары җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Лебедино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Березовая Грива авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 группа инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә,түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- җирлек эчендәге юлларга таш түшәү һәм аларны карап тоту;
- су белән тәэмин итү системасын карап тоту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Лебедино авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.»

3. Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең Березовая Грива авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru.), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Лебедино авыл җирлеге башлыгы ______________ Тюкарев Ю.И.
(имза) (имзаның расшифровкасы)